КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 12 апрель г.Казань № 237

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы СПИДка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия составын раслау турында» 2005 ел, 6 сентябрь, 438 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы СПИДка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы СПИДка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия составын раслау турында» 2005 ел, 6 сентябрь, 438 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 29 гыйнвар, 21 нче; 2007 ел, 20 август, 399 нчы; 2007 ел, 6 декабрь, 690 нчы; 2009 ел, 25 май, 335 нче; 2009 ел, 24 декабрь, 871 нче; 2010 ел, 31 август, 688 нче; 2012 ел, 19 июнь, 523 нче; 2014 ел, 17 гыйнвар, 19 нчы; 2015 ел, 4 март, 133 нче; 2016 ел, 17 май, 320 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы СПИДка каршы көрәш буенча ведомствоара комиссия составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

комиссия составыннан Г.Ю.Вафинны, Л.Ю.Глухованы, Э.Н.Фәттаховны чыгарырга;

комиссия составына түбәндәгеләрне кертергә:

Садыйков Марат Наил улын – Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрын;

Борһанов Рәфис Тимерхан улын – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасарын – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрын;

Заһидуллин Рөстәм Илдус улын – Татарстан Республикасы юстиция министрын.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин